ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИШЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

2024 ел, 18 ноябрь №93

«Җир салымы турында»карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 40 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«2) әлеге абзацта күрсәтелгән һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш, торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,15 0,15 процент;»;

2 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3)әлеге абзацта күрсәтелгән һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләреннән тыш, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,15 процент;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Ишеево авыл җирлеге башлыгы,
Ишеево авыл җирлеге Советы Рәисе Р.Р. Сатдинов